ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____07.07.2023__________ Казан ш. № _____153____

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Билгеләргә:

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан кадрлар һәм юридик эш бүлеге катнашында башкарыла;

коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль рәвештәге мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы була.

3. «Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибен раслау турында» 2018 елның 20 июлендәге 76 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2023 елның ____ ________________ №____ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетына гражданнардан коррупциячел юнәлешле фактлар буенча килгән мөрәҗәгатьләр белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) коррупция һәм ришвәтчелек фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турында белешмәләрне үз эченә алган коррупция юнәлешендәге фактлар буенча, шулай ук Дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булып тормаган вазыйфаларны били торган һәм Дәүләт комитетында эшчәнлекне техник яктан тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыра торган эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан кылынган, хезмәт хәленнән явызларча файдалану билгеләрен үз эченә алган башка гамәлләр турында гражданнардан алынган мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгать) карау үзенчәлекләрен билгели. Бүтән затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 3 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү алар компетенциясенә карый торган тиешле органга яки тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләрне кабул итү ысуллары:

1) язма рәвештә (гариза бирүче тарафыннан шәхсән, почта аша, кулдан, башка төрле юллар белән);

2) электрон рәвештә ( tourism.rt@tatar.ru адресына электрон почта аша, Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының рәсми интернет-сайтында «Электрон кабул итү» системасы аша: https://tourism.tatarstan.ru/ (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты);

3) коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча (843) 222-90-29 «ышаныч телефоны» буенча;

4) эш көннәрендә гражданнарны шәхсән кабул итү барышында.

3. Мөрәҗәгать «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, мөрәҗәгать компетенцияләренә ярашлы рәвештә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

4. Кадрлар һәм юридик эш бүлеге тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе үткәрелә башлый (хезмәткәрдән язма аңлатмалар соратып алына).

5. Хезмәт тикшерүен үткәргән комиссия бәяләмәсе нигезендә коррупция билгеләре булу турындагы фактлар расланган очракта, комиссия бәяләмәсе алынган көннән соң өч эш көне эчендә рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенә (алга таба – Комиссия) күрсәтмә кертә. Хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре, шулай ук хезмәткәрнең язмача аңлатмаларын анализлау буенча әзерләнә, кылына торган яисә кылынган законга каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында билгеле булган очракта, тиешле мәгълүмат компетенцияләре нигезендә хокук саклау органнарына комиссия бәяләмәсен алу көненнән соң өч эш көне эчендә җибәрелергә тиеш.

6. Мөрәҗәгать җибәргән гражданинга җавап әзерләү Дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

Кадрлар һәм юридик эш бүлеге Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасы аша Дәүләт комитетында коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка мөрәҗәгать итү буенча гражданинга җавап җибәрү срогы беткәнче кимендә 15 көн алдан язма тәкъдимнәр җибәрә.

7. Әгәр мөрәҗәгатьтә Дәүләт комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында мәгълүмат булса, аңа бер эш көне дәвамында әлеге мөрәҗәгатьне караганда мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча чаралар күрергә, шул ук вакытта үзенең турыдан-туры җитәкчесенә һәм Комиссиягә дә хәбәр итәргә кирәк.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты боерыгы проектына килештерү кәгазе

«Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетында коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрне алу ысуллары турында»

| т/с | Вазыйфасы, фамилиясе, инициаллары | Имза һәм килештерү датасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| КИЛЕШТЕРЕЛДЕ | | | |
| 1. | Кадрлар һәм юридик эш бүлеге башлыгы Л.И.Миңнебаева | | |
| ӘЗЕРЛӘНДЕ | | | |
| 2. | Кадрлар һәм юридик эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты А.М.Гущенкова | | |

«____» ____________ 20___ ел.________________ (___________________)

(дата, эшне алып бару өчен җаваплы хезмәткәрнең визасы)